БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ**
31 май 2019 ел

**КАРАР**
№ 188

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставының 29, 53 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2005 елның 27 декабрендәге 26 номерлы карары белән расланган (2010 елның 17 декабрендәге үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Нигезләмәнең 5.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Үз вәкаләтләре чикләрендә Палата исеменнән карарлар һәм күрсәтмәләр чыгара. Хокукый актлар аларга кул куелган көннән үз көченә керә, әгәр акт белән башкасы каралмаган булса. Палата рәисенең хокукый актлары муниципаль Район территориясендә урнашкан барлык предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, иҗтимагый һәм дини берләшмәләр, шулай ук гражданнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан үтәлергә тиеш.».

2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә baltasi.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы рәисе

Р.Р.Нотфуллин